ТР Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе

Тема. **Әдәбиятта – терроризм. Татар халык әкиятләрендә явызлык чыганагы булган геройлар, аларның үзенчәлеге.**

**Укучы: Мәрданов Сәйдәш, 5 класс**
**Укытучы: Мәрданова Әдилә Әхсән кызы.**

**Апрель, 2022 ел**

ПЛАН

**КЕРЕШ**

**I. Терроризм нәрсә ул?**

**II. Терроризм тарихы.**

III. Әдәбиятта – терроризм. Татар халык әкиятләрендә явызлык чыганагы булган геройлар, аларның тоткан урыны.

**ЙОМГАКЛАУ**

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

## КЕРЕШ

**Террори́зм** – ул сәясәт, системалы рәвештә куллануга нигезләнгән. «Террор» ( латыйн теленнән кергән *terror – “курку», «кот алыну»)* сүзенең синонимнары булып «көчләү», «куркыту» сүзләре тора. «Террор дәвере»ннән соң бу термин бик күп илләрдә киң тарала.

Юридик көче булса да, бу терминның төгәл аңлатмасы юк. Ләкин белгечләр шундый фикердә: терроризмның иң яхшы билгеләмәсе – сәяси, идиологик, экономик, дини максатларга көчләү юлы белән ирешү.

Тарихка күз салсак, терроризм инде безнең эрага кадәр үк күзәтелә. Кешеләрне куркытып, котларын алып торган секталар, кабиләләр булган һәм, минем уйлавымча, бу һичшиксез халык авыз иҗатында чагылыш тапкан. Чөнки халык үзенең тормышының һәр ягын, проблемаларын, чыгу юлларын фолклер жанрларының төрле әсәрләрендә күрсәткән. Ә террор золым, явызлык, куркыту сүзләре белән аваздаш буларак, билгеле инде, әкиятләрдә чагылыш тапкандыр дигән **фаразны** алга куям.

Максатым, чыннан да, әкиятләрдә терроризм һәм аңа каршы көрәш чагылыш табуын күрсәтү.

Максатыма ирешү өчен, җитәкчем белән бергә, түбәндәге бурычларны билгеләдек:

1) террор, аның тарихы, аның төрләре, аның белән көрәш юллары турыда өйрәнү;
2) үзебезнең татар халык әкиятләрен уку;
3) явызлык, золым күренешләре булган әкиятләрне аерып алу;
4) андагы явыз көчләрне, аларның характер сыйфатларын билгеләү, аларга каршы кулланылган көрәш юлларын аерып алу;
5) аерып алынган мәгълүматларыма һәм фәнни хезмәтләргә нигезләнеп фаразымның дөреслеген яки дөрес булмавына нәтиҗә ясау.

## I. Терроризм нәрсә ул?

Террор - ул кешеләр группасына оешкан, үз максатын көчләү аша ирешергә омтыла торган авыр җинаять. Террористлар - алар кешеләрне көчләп алучы, күп җыелыш урыннарында шартлау оештыручы, корал кулланучы кешеләр, бик еш аларның эшеннән гаепсез кешеләр җәфалана, алар арасында шулай ук балалар да була.

Субъектның характеры буенча терроризм 2 төрле:

- индивидуаль (ялгызык террорчы) — бу очракта, бер-ике кеше тарафыннан эшләнә, ә аның артында ниндидер оешма торырга мөмкин. Мондый терактларны гадәттә психик яктан авыру кешеләр башкара;

- коллектив терракт – ниндидер оешма тарафыннан кылына һәм ул хәзерге заманда киң таралган төре.

Максаты буенча милли, дини һәм социаль төрләргә бүленә. Милли изү яки ирек өчен көрәш,динара көрәш һәм ил эчендәге экономик, сәяси системасын үзгәртергә тырышуга нигезләнергә мөмкин.

Террор белән көрәш ничек алып барыла соң? Бу юнәлештә тикшерүләр алып баручы белгечләр терроризм белән көрәшнең ике юнәлешен күрсәтәләр: «прогрессив», ягъни террорчыларның таләпләрен өлешчә үтәү һәм «консерватив» юл – террорчыларны, аларның хуплаучыларны тулысынча юкка чыгару, аларга каршы көрәштә ярдәм иүчеләрне бүләкләү, террористлар белән бернинди сөйләшүләргә, килешүләргә бармау.

Белгечләрнең фикере төрле, кемнәрдер беренче юлны яклаcа, икенчеләр террорчыларны бары тик көч белән генә җиңеп була дигән фикерне ассызыклый, аларны юкка чыгарырга, тамырларын корытырга кирәк диләр.

## II. Терроризм тарихы.

Тарихка күз салсак, иң зур террор актларын тарихчылар 1921 елдан башлап күрсәтә. Белгечләрнең фикерләре бу очракта да бүленә: ерак үткәндәге вакыйгаларны, бүгенге терминологиягә нигезләнеп бәяләп буламы. Шул фикерләргә нигезләнеп, чорларны карап үттек.

**Борынгы дөньяда терроризм.**

А.А.Королев фикеренчә, инде безнең эрага кадәр 340 ел элек Александр Македонскийның этисе теракт нәтиҗәсендә үтерелгән дип саный. Башка тарихчылар иң борынгы террористик төркем дип сикарийлар (хәнҗәрчеләр) яһүд сектасын саный. Алар безнең эраның I гасырында югары катламга каршы көрәшкән милләтчеләр була. Аларның хәрәкәтләрендә дини фанатизм һәм сәяси террор чагылыш таба.

**Урта гасырларда терроризм.**

Урта гасырларда террорның классик мисалы булып ассасиннар сектасы («үлән ашаучылар») тора. Алар үз чорларында бик күп идарә династияләренең тынычлыгын ала, бик күп идарәчеләрне үтерәләр, үзләре монгол-татарлар тарафыннан юкка чыгарыла.

**Яңа чор терроризмы.**

Бу чорда сәячәтчеләр дүрт глобаль террор дулкынын күрсәтә: анархизм, антиколониаль, «яңа суллар» һәм глобализация белән бәйле, хәзерге заманда да дәвам итүче терроризм.

«Терроризм сәбәпсез килеп чыккан һәм кешелекнең биологик табигатенең кимчелекләендә тамыр җүюче нәрсәдер түгел. Ул – икътисади күренеш, тамырлары кешеләрнең икътисади яшәү шартларында», ди А, А, Зиновьев. («Как убить слона иголкой», 2005)

Россия Федерациясенең Хокукый Кодексында (ст.205) терроризм җинаяте карала һәм гомерлек иректәр тыю белән хөкем ителә. Статья буенча терроризм – җирле халыкны куркытучы һәм кешенең үлем куркынычын тудыручы шартлату, ут төртү һ.б. шундый хәрәкәтләр; хакимиятнең яки халыкара оешмаларның

карарына йөгынты ясау максатыннан шактый зур мал-мөлкәткә шактый зур югалтуларга китерү яки басып алу, башка авыр нәтиҗәләр һәм шундый хәрәкәтләр булдыру куркынычы тудыру.

## III. Әдәбиятта – терроризм. Татар халык әкиятләрендә явызлык чыганагы булган геройлар, аларның тоткан урыны.

Әдәбият белән җәмгыять һәрвакыт бер юнәлештә бара, чөнки матур әдәбиятта халыкны кызыксындырган, борчыган проблемалар күтәрелә, аларның

тормышы көнүзәк тема буларак чагылдырыла, халык геройлары, аларның характер сыйфатлары әдәби образларда бирелә. Шуңа күрә тарихтагы терроризм кебек куркыныч вакыйгалар, террорчылар турында матур әдәбиятта да һичшиксез бар. Бу бигрәк тә тарих, тарихи вакыйгалар чагылыш тапкан әсәрләрдә. Җитәкчем белән без андый әсәрләрне дә карап чыктык, ләкин үзебезнең сыйныф әдәбият дәресләрендәге өйрәнелгән халык авыз иҗаты жанры минем өчен бүгенге көндә якынрак һәм аңлаешлырак та. Шуңа күрә без татар халык әкиятләренә тукталдык.

Татар халык әкиятләрендә халыкны куркытучы, аларның тормышына куркыныч тудыручы яки халыкка золым, явызлыклар кылынган вакыйгаларга нигезләнгән әкиятләрне барладык. Аларда халыкны куркыту, аларга авырлык, кайгы-хәсрәт, фаҗига китергән вакыйгаларны, явыз геройларны барладык. Аларның характер сыйфатларын, портретларын, үзенчәлекләрен билгеләдек. Аларга нинди җәза бирелгәненә дә игътибар иттек. Шуларга карап нәтиҗә ясадык.

**«Камыр батыр»** әкиятендә **Җен карты** авыл халкын куркытып тора, аларга янап үзенә ашарга бирүләрен аләп иткән, алардан талап байлык җыйган һәм иң куркынычы – яшь кызларны урлап ябуда тоткан, аңа хезмәт итәргә мәҗбүр иткән. Шулай ук **Аждаһа елан** «һәр елны бер вакытта килеп Сәмругның балаларын ашап китә икән». Бу образларның характер сыйфатларына, төс-кыяфәтләренә игътибар итеп, язып алдык.

**Җен карты**. «Үзе бер карыш-сакалы биш карыш бер карт», ул һәрвакыт фәрман гына бирә: күтәреп керт, күтәреп утырт, ашны казаны белән бир. Шуларга «рәхмәт йөзеннә» кыйнап та китә. Бик астыртын, хәйләкәр. Ләкин куркак. Камырбатыр аны сакалыннан каенга бәйләп куя – җен карты сакалын өзеп, юлында каннарын тамыза-тамыза качкан.

**Аждаһа.** Кешеләргә генә түгел, табигатькә дә бик зур зыян салучы.

Әкият ахырында бу зыян салучыларга нигәдер җәза бирелми, геройлар «пргрессив» юлный сайлыйлар.

**«Гөлчәчәк» экиятендә Убырлы карчык** - «бик явыз, гомергомергә яхшы кешеләрне аздырып, батырларны юлдан яздырып йөргән, ди. Карчыкның улы, анасының явызлыгына түзә алмыйча, дөнья гизәргә, бәхет эзләргә чыгып киткән», «Гөлчәчәкне каенанасы - убырлы карчык - бер җиргә дә чыгармый икән, үзе төннәрен яхшы кешеләрне аздырырга, батырларны юлдан яздырырга чыгып киткәндә дә киленен өендә бикләп калдыра икән, ди» Бүре сурәтенә керә алган. Шушы явызлыкларына каршы хәтта табигать тә каршы чыккан. Җәзасы - «Гөлчәчәкнең абыйсы Соры бүрене бәреп үтергән», «консерватив» юлны сайлаганнар.

**«Таңбатыр»** экиятендә патшалыкны куркытып торган **Дию пәриләре** турында сүз бара. Алар бик көчле, бик куркыныч, кешеләрне дә кабып кына йота, явыз, мәкерле, масаючан һәм астыртын, хәйләкәр итеп тә характерлана. Һәм алар кеше сурәтендә, атка атланып йөриләр, сарайда торалар, эт тә ияртkәннәр. Мәсәлән, өзекләрдә болрар бик яхшы күренә; «бик каты җил-давыл чыга да кызларның өчесен дә күтәреп алып китә», «бу давыл шулхәтле көчле була, юлына туры килгән калын-калын агачларның башларын кыеп кына алып китә икән», «әлеге җил-давыл бер җирдә бөтерелеп, котчыккыч булып өерелеп-өерелеп тора да бер биек тау башына барып туктый. Тау башында бик яман бөтерелеп тора-тора да бик ямьсез бер нәрсәгә - дию пәриенә әверелә», «дию патша кайтып керсә, тотып ашар үзеңне», « җил-давыл куптарып, дию бакыр күпергә якынлаша башлый. Күпер янына иң элек моның эте килеп җитә. Диюнең эте күпер янына килеп җитә дә, күпергә кермичә, шыңшып, хуҗасы янына кире китә. Дию аңа камчысы белән генә селтәп, атына атланган килеш күпергә барып керә. Күпергә барып керү белән моның аты да шып туктый». Бу явыз җан иясен җәза - «Таңбатыр (өчесен дә) күтәреп сала да, кылычын суырып алып, диюне тураклап, әрдәнә итеп өеп куя».

Алдагы экият «**Таңбарыр**»да да шундыйрак сюжет: **Дию патшасы** бер патшалыкка һөҗүм итә, аның хатынын да алып китә, балаларын ятим итә. **Дию патшасы** куркыныч, явыз итеп бирелә, кеше ите белән туклана – гомумән

халыкка бик күп кайгы-хәсрәт, фаҗига чыганагы булып торган: «тугыз башын тугыз якка салып, бернәрсә белмичә, җәйрәп йоклап ята», «монда тагын безнең кардәшләребез бар, аларны да коткарыйк, - диде. Егеткә ачкычларны биреп, сарайларны тикшерергә киттеләр. Бер сарайны ачып җибәргәннәр иде, күрделәр: сарай тулы картлар икән. Бу картләр диюнең гадәтен белеп: «Симезебезне тотып ашар инде»,— дип, куркытып кача башладылар», «тагын бер сарайны барып ачкан иде, анда карчыклар яталар икән. Алар да куркышып: «Монысы симез, монысы симез»,— дип, берсен-берсе күрсәтә башладылар», «сарай диюнең тегермәне иде. Ул, шул тегермәндә әлегә хәтле ничә меңнәрчә адәмнәрне тарттырып, азык итеп ашады. Менә инде күрәсез, бу дию ничә еллардан бирле никадәр кешенең башына җитте». Ә Дию пәриенә җәза - «диюнең тугыз башын тугыз җиргә кисеп ташлады»

**«Чәчәкле күлмәк»** экияте. Монда су астында яшәүче **Аждаһа** зур бер патшалыкның котын алып тора:«Әй, улым, ашарга бик пешерер идем дә, бездә, җиде башлы аждаһа ята суда,беркемгә дә су бирми, төнлә бер чиләк бирә, артыгын бирми». Шуңа өстәп: «ул аждаһа чиратлап кеше ашый, ансыз бер тамчы да су бирми ул. Бүген патша кызына чират, шуңа кара байрак асылган, кайгылы көне патшаның». Аждаһа берәү генә дә түгел: «алар чиратлашып чыгалар, бүген җиде башлысы иде, хәзер аның тугыз башлысы чыга, өч кызын да ашый хәзер, өч аждаһа». Монда тагын бер явыз образ **Юха елан** «аждаһа шундый да матур егеткә әйләнгән, аның кебек егет дөньяда юк, шундый матур». Шул матурлыгы белән алдап явызлыклар кыла. Аларга да тиешле җәза бирелә экияттә «егет кылычын тотты да, тегенең авызына кереп, урталай ярып ук чыкты. Аждаһа селкенгән иде — урталай ярылды, башларын чапкалый да таш астына кыстырып куя инде, зур таш астына», иенчесен дә шунңый җәза көтә «Тугыз башын да чаба да таш астына кыстырып куя. Гәүдәсен тураклап суга ыргыта». Ә өченчесе Юха елан – хәйләләп «унбер башның чаба, берсе калгач, ялынып калдырта, чуен подвал ясатып, шул подвалга ябып куялар моны», ләкин барыбер «суда көенә чабып өзә башын **Юха**ның».

Әкиятләрне анализлап чыкканнан соң шундый **нәтиҗәләргә** килдек. Мондый явызлыклар кылучы геройлар нигездә тылсымлы әкиятләрдә. Алар мифик образлар. Иң киң таралганы – **Дию.** Ул, кагыйдә буларак, кешеләрдән еракта, Каф тавы артында яисә җир астында яши һәм, гадәттә, патша кызларын яки аның мал-туарын урлап китә. Аның биләмәсенә беркемнең дә керергә хакы юк. Анда бик күп кеше сөякләре аунап ята. Мондый күренешләр диюнең үлеләр дөньясы хакиме булуын раслый. Ләкин дию нинди генә куркыныч зат булмасын, әкият герое — баһадир егет, юлда очраган теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп, аның биләмәсенә керә һәм, аны үтереп, тиешле җәзасын бирә. Шулай ук **Убырлы карчык** персонажы сурәтләнә. Кайберләрендә ул җалмавыз, сихерче карчык яисә бер карчык дип кенә йөртелә. Ләкин асылда бу исемнәр бер үк затны белдерәләр. Күбесенчә урмандагы кечкенә өйдә яшәүче убырлы карчык (җалмавыз) усал һәм рәхимсез. Ул кешеләрне йота яисә аларның канын эчә. Әкиятләрдә еш очрый торган елан персонажы, ул күп очракта аждаһа образы белән кушылган. Шуңа күрә кайбер әкиятләрдә бу персонаж аждаһа-елан дигән кушма исем белән дә йөртелә. Халыкта еланның, йөз ел яшәгәч, аждаһага әверелүе турында ышану бар. Ә аждаһа, янәсе, дөньяда мең ел яши һәм, үз чиратында, юхага әверелә. **Аждаһа** берничә башлы итеп сурәтләнә (ике, өч, дүрт, алты, җиде, тугыз, унике башлылары очрый). Аждаһа, гадәттә, диңгездә яисә елга буенда яши һәм кешеләргә бер тамчы да су бирми. Су алыр өчен кешеләр аңа кызларын корбан итәргә мәҗбүр. **Юха да** — кешенең дошманы. Ләкин ул аждаһа кебек ачыктан-ачык хәрәкәт итми, бәлки, матур егет яисә матур кызга әверелеп, башта кеше белән никах мөнәсәбәтенә керә, шуннан соң әлеге кеше әкренләп сула башлый. Юха дошманын соңгы чиккәчә эзәрлекли. Бу затлардан тыш, тылсымлы әкиятләрдә, явыз зат буларак, үзе бер карыш, сакалы биш карыш карт, гыйфрит, җен, пәри һ. б. мифологик персонажлар да очрый. Ләкин алар барысы да, нинди генә явызлыклар эшләмәсен, халыкны дер калтыратып тормасын – тиешле җәзасын алалар.

Тагын бер үзенчәлеге, алар кешегә охшаган, төс кыяфәт, холык-фигыль. Ләкин бик нык ямьсез, коточкыч чиктән тыш явыз һәм куркыныч.

## ЙОМГАКЛАУ

**“Terror” –курку, дәхшәт дигәнне аңлата. Бу сүзне бүген дөньяда белмәгән кеше юктыр. Кешеләр бу күренеш алдында үзләрен яклаучысыз, көчсез итеп тоя. Бу бик зур проблема Кешелек дөньясы өчен. Ул күп кенә илләрне биләп алды.**

Һәр халыкның үз менталитеты, ул бик күп факторлар йогынтысында формалашкан. Бу территория, аның урнашуы, халыкның эш төре һәм тарихи үткәне, аның ни дәрәҗәдә катлаулы булуыннан да тора. Һәм болар барысы да халык авыз иҗатында – фольклорда чагылыш таба. Андагы вакыйгалар һәм бигрәк тә андагы геройларда. Мәсәлән, экиятләрдәге коточкысыз куркыныч затлар халыкның нәрсәдән курыкуын, аларның характер сыйфатларын нәрсә ныгытуын, аларда нәрсә уңай фикер уятуын, ә нәрсәнең тискәре фикер уятуы турында сөйли.

Ә без караган экиятләрдән шул аңлашыла: халыкта борынгыдан ук нәрсәдәндер курку яисә сагаю булган. Һәм алар тормыштан алынгандыр. Тарихи фактлар да шуны сөйли. Кешеләр шул экиятләр аша аңа каршы көрәш юлын күрсәткән. Бердәмлек, көч, ярдәмчеллек, бер-береңә ихтирамлы булу гына явызлыкны җиңә. Ә явызлык һәрвакыт җиңелә.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Ахметова Ф.В. Маҗаралы экиятләр турында. Казан 1976 ел

2. Насыйри К. Саланма әсәрләр, икенче том. Казан, 1975 ел.

3. Татар халык иҗаты. Төзүчеләр: Ярми Х.Х., Шамов А. һәм Х. Госман. Казан, 1954 ел

4. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Казан 1977 ел

5. Татар халык әкиятләре. Казан 1958 ел

6. Яшәгән, ди, булган, ди. Әкиятләр. Казан “МӘГАРИФ” НӘШРИЯТЫ, 2000 ел

7. Татарча экият "Камыр батыр"|Татар халык әкиәте | (tatar16.ru)

8. Терроризм — Википедия (wikipedia.org)